# Мәктәп хәбәрчесе

**№5** (№8) май 2019 ел

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


**/Мөхәррир сүзе /**

### *Балалар иминлеге – уртак бурычыбыз!*

Менә зарыгып көтеп алган җәй дә килеп житте. Алда балаларны өч айга сузылган ял, төрле уеннар һәм рәхәтләнеп күңел ачу көтә. Укучыларның сәламәтлеге һәм тормыш иминлеге турында кайгырту-мәктәпнең, педагогик коллективның, ата-ананың һәм баланың үзенең иң мөһим бурычы. Шуңа күрә без балаларга һәртөрле куркыныч очракларда үзләрен ничек тотарга кирәклеген өйрәтәбез. Бигрәк тә әңгәмәләр оештыру, төрле куркыныч очраклар һәм вакыйгалар буенча сөйләшүгә әһәмият бирәбез.

Һәр кеше үзенең гаиләсе, балалары, туганнары, ата-анасы белән дөньяның тәмен белеп, матур гына яшәп ятканда хәвеф-хәтәр бездән бер адым ераклыкта гына йөри. Бер генә ялгышлык эшләсәң, шунда ук зур бәхетсезлек һәм каза килеп чыгарга мөмкин. **Куркынычсызлык кагыйдәләрен белмәү һәм үтәмәү, игътибарсызлык һәм җавапсызлык еш кына бәхетсезлеккә һәм фаҗигале хәлләргә китерә.**

Тормышта киң таралган бәла-казаларның берсе – **янгын**. Халыкта шундый мәкаль бар: "Карак керсә берне ала, ут берни дә калмый". Иң аянычы шул, районыбызда да янгыннар чыгып тора һәм аларның фаҗигале тәмамланганнары да шактый. Алар арасында ут чыгуда бөтенләй гаепсез кешеләр дә күп: күрше-күләннәр, балалар, карт-корылар һәм янгын сүндерүчеләр... Янгын чыгу куркынычы бигрәк тә җәйге чорда арта. Һәр бишенче янгын очрагы балаларның ут белән шаяру нәтиҗәсендә килеп чыга. Төп сәбәп — балаларның караучысыз калуында. Өлкәннәргә бала-чаганың кызыксынучан булуын онытмаска кирәк. Балалар бит зурларга охшарга тырыша. Өлкәннәр өчен шырпы ризык әзерләү, яисә мич кабызу өчен хезмәт итсә, балалар кулына эләккәч ул куркыныч коралга әверелә.

Җәйге каникул көннәрендә балаларны юл-транспорт травматизмынын-нан саклау да ата-аналар һәм укытучылар өстенә йөкләтелгән. Статистика күрсәткәнчә, балалар катнашындагы **юл һәлакәтләре** каникуллар чорын-да аеруча арта. Велосипедта йөргәндә тиешле урыннардан гына йөрергә, транспорт юлына чыкмаска, хәрәкәтчән уеннарны бары тик балалар мәйданчыкларында гына уйнарга кирәклеген даими искәртеп торырга кирәк. Каникул көннәрендә күп кенә балалар шәһәрдәге туганнарына кунакка бара. Мондый очракта шәһәр шартларына күнмәгән баланың юл-транспорт казасына очрау мөмкинлеге тагын да зур.

Җәй көне өлкәннәрдән башка су буйларына барырга һәм суга керергә ярамавын бала һәрчак истә тотырга тиеш. Безнең шартларда **суга бату** куркынычын Чирмешән елгасы һәм тирән күлләр тудыра. Тирәнлеге һәм төбенең торышы билгеле булмаган, коенырга яраклы дип табылмаган сулыкларга керү бату куркынычын тагын да арттыра.

Балаларның ял вакытын хәвефсез итү максатыннан кече яшьтәге балалар өчен **мәктәп лагерьлары** оештыра. Быел безнең мәктәптә лагерь **3-27 июнь** көннәрендә эшләячәк. Биредә балалар тәрбиячеләр күзәтүе астында ял вакытларын файдалы итеп үткәрәләр, сәламәтлекләрен ныгыталар. Каникулның калган көннәрендә балалар тулысынча диярлек өлкән гаилә әгъзалары карамагында кала. Шулай итеп, балалар иминлеге өчен төп җаваплылык та ата-аналар өстенә төшә. Җәйге ял вакытында көндәлек режимны саклау да әһәмияткә ия. Сәламәт яшәү рәвеше, нинди дә булса бер шөгыле булу - ялның файдалы булуына шарт булып торачак.

***Фәнүзә Гафиятуллина. Мөхәррир, ана теле һәм әдәбияты укытучысы***

### *25 май*
### *“Соңгы кыңгырау” бәйрәме*



**Сез таралгач, мәктәп бушап калыр,**
**Тәрәзәләр карар ямансу.**
**Кыңгырау чыңында моңлы сагыш,**
**Сау бул, мәктәп, җитте хушлашу.**

**Олы юлга сезне озатабыз,**
**Теләкләрнең юллап изгесен,**
**Сездән килсен шатлыклы хәбәрләр,**
**Укучы ул — мәктәп көзгесе.**

**Туган мәктәпне сез онытмагыз,**
**Ул – белемнең тәүге бишеге.**
**Сезне мәктәп сөенеп каршы алыр,**
**Һәрчак ачык аның ишеге.**

**Барыр юлларыгыз якты булсын,**
**Гел кояшлы килер көнегез.**
**Хыялларны тормышка ашырып,**
**Белем үрләренә менегез,**
**Һәрчак кеше була белегез.**



## *9 май – Җиңү бәйрәме*



Җиңү бәйрәмен мин һәрьелны дулкынланып көтеп алам. Чөнки сугыш афәте безнең гаиләгә дә зур югалтулар китерә. Карт әбиемнең өч энесе сугыш кырларыннан әйләнеп кайтмый. Габдрахман абый 1942 елның салкын кышында Мәскәү өчен барган сугышларда хәбәрсез югала. Зөфәр абый 1942 елны әсирлеккә эләгеп, Идел-Урал легионында була. Муса Җәлилләр белән бергә татар әсирләрен легионга җыю белән шөгыльләнә. Гестапо төрмәләре аркылы узып, 1945 елның язында эзләре югала. Карт әбинең кече энесе Исмәгыйль абый 1944 елның гыйнварында Белорусиядә барган сугышларда 18 яшендә һәлак була.

Бабамның әтисе Габделәхәт бабай Бөек Ватан сугышында башыннан ахырына чаклы катнаша. Ул 1941 елның сентябрендә фронтка алына. Сугышка кергән вакытта алар биш кешегә бирелгән бер иске винтовка белән дошманның яңа танкларына каршы торырга тиеш булалар. Башта Габделәхәт бабай Финляндия фронтына җибәрелә, ә аннан 1941-1942 елның кышында Курск шәһәренә һөҗүмдә катнаша. 1942 елның көзендә бабайлар Сталинградны сакларга җибәрелә. 1943 елның җәендә Габделәхәт бабай үзе сугышка чаклы шахтада эшләгән Донбассны, ә аннан соң Көньяк Украинаны азат итүдә катнаша. 1944 елның маеннан алып бабай разведчик булып хезмәт итә һәм сугышны Берлинда тәмамлый.

Габделәхәт бабай 1945 елның июлендә демобилизацияләнә. Сугыш барышында ул дүрт тапкыр яралана. Бер пуля аның күкрәк астыннан кереп, үтәли тишеп чыга. Аннан соң биленә граната кыйпылчыгы кадала һәм тез капкачы каерыла. Варшава снайперы пулясыннан бабайның күкрәк читлеге йөрәге күренерлек дәрәҗәдә ертылган булган. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Габделәхәт бабай III нче дәрәҗә Дан ордены, “Отличный разведчик” билгесе, “Варшаваны азат иткән өчен”, “Берлинны алган өчен”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре белән бүләкләнә.

**Сара Насыйрова, VIII сыйныф укучысы**

## *Балачакның соңгы бәйрәме*



Май аеның соңгы көннәре быел кояшлы килде. Ләкин 25 май башка көннәрдән ничектер аерылып тора. Бер үк вакытта күңелле дә, моңсу да. Бүген бит соңгы кыңгырау бәйрәме. Һәр елны, чыгарылыш имтиханнары алдыннан, IX, XI сыйныфлар өчен чыңлый ул соңгы кыңгырау. Җилкәләреннән аркылы салган тасмалары аларны барыбыздан да аерып тора. Мәктәптә алган белемнәренә нәтиҗә ясау чоры җиткәнлектән, йөзләрендә шатлык та, җаваплылык та, борчылу да чагыла.

Бәйрәмне XI сыйныфтан Илсур абый белән Нәзилә апа башлап җибәрде. Мәйдан түренә очар кошлар сыман тезелеп баскан чыгарылыш сыйныф укучылары, үзләренең шигырьләрен сөйләп, җырларын җырлап, мәктәп белән хушлаштылар. Мәктәп директор Рафик абый укучыларга олы тормышка аяк басканда изге теләкләр теләде, аларга белем һәм тәрбия бирүдә зур көч салган укытучыларга, ата-аналарга рәхмәтен белдерде. Аннан соң җирле идарә башлыгы Энҗе апа сүз алып, бәйрәмдә катнашучыларны авыл җирлеге һәм район җитәкчелеге исеменнән котлаулар җиткерде. Бәйрәм барышында төрле фән укытучылары, әти-әниләр, мәктәп ветераннары чыгарылыш сыйныфларга киләчәк тормышларында уңышлар; туган җирләренә, гаиләләренә тап төшермәүләрен, имтиханнарны уңышлы тапшыруларын теләделәр.

Котлаулардан соң мәйданга быел беренче сыйныфка баручы балалар чыкты. Мәктәпнең бакча төркемен тәмамлаган өч егет бик матур итеп шигырьләр сөйләделәр. Татарча биюне искиткеч итеп, һәркемне дәртләндерерлек итеп башкардылар. Аларга тәрбияче Гөлүсә апалары һәм XI сыйныф укучылары бүләкләр өләштеләр. Бәйрәмнең ахырында мәктәпне тәмамлаучы укучылар, үзләренә алмашка килүче сабыйларны җилкәләренә алып, кыңгырау чыңлатып, мәйданны урадылар.

Әй, кыңгырау... Бу мәктәп тарихында син ничәмә кат чыңладың икән? Синең яңгыравыклы авазың, балачакның якты хатирәсе булып, күңелләрдә мәңгегә уелып калыр. Ә бүгенге бәйрәм кыңгыравы, чыгарылыш сыйныфларга зур тормышның башлануын искәртсә, беренчегә баручыларны күңелле мәктәп тормышы көткәнен игълан итте.

**Бәйрәм репортажын VII сыйныф укучылары Зөлфирә Сафиуллина һәм Виктория Нукина әзерләде**

## *Пар канатлы мөгаллимнәр* 





Һәр төбәкнең хөрмәткә ия шәхесләре бар. Безнең авылда да, әлбәттә, бар алар. Уку елы төгәлләнер алдыннан, гәзитебезнең редколлегия әгъзалары Түбән Майна мәктәбенең горурлыгы булган, гомерләрен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган мөхтәрәм ветеран укытучыларыбыз Лилия апа һәм Замир абый Сафиннар белән очрашты.

- Замир абый, Лилия апа, нинди уку йорты тәмамладыгыз? Кем Сезгә шушы һөнәргә юнәлеш бирде? Хезмәт юлыгыз кайда башланды?

**- Без кечкенәдән үк укытучы булырга хыялландык. Югары уку йортын тәмамлагач, һөнәребезгә тугры калып, шушы якларга рус теле һәм немец теле укытучылары булып килдек**.

- Замир абый, Сез бит икегез дә чыгышыгыз белән Түбән Майнаныкылар түгел. Бу авылга кайчан килеп урнаштыгыз? Чит авылда тормыш башлау авыр булмадымы, халык укытучыларны ничек кабул итте?

**- Без бу авылга 1965 елда, сигезъеллык мәктәп ачылган елны килеп төпләндек. Авылны бик яраттык, чөнки халык укытучыларны хөрмәт белән каршы алды. Шуңа күрә яшь чакта тормыш башлау бернинди кыенлыклар тудырмады. Авыл халкы гади, үзара ярдәмләшү дә көчле иде. Шунлыктан бу авылны үз иттек, китү турында уйламадык та.**

- Ул чорларда мәктәп укытучылары нинди кыенлыклар кичерә иде?

**- Дәверенә күрә бәлки булгандыр да кыенлыгы, ләкин алай берсе дә күңелдә калмаган. Балаларны, үз эшебезне бик яраттык. Ә күңел биреп башкарган эшнең кыенлыгын тоймыйсың аның**.

- Лилия апа, тәүге дәресегезне, беренче укучыларыгызны хәтерлисезме? Алар белән очрашканыгыз бармы?

**- Әлбәттә, хәтерлибез. Мәктәптә Түбән Майнадан гына түгел, күрше Чуаш Майнасыннан да балалар укый иде. Без эшли башлаган елда беренче сыйныфка Сәкинә апагыз керде. Бишенче сыйныф укучылары булып Хәлимә, Румия апаларыгыз килде. Барлык укучыларыбызны да бүгенгедәй хәтерлибез. Шушы авылда яшәгәч алар белән даими очрашып торабыз. Хәлләребезне белеп торалар**.

- Замир абый, хәзерге заман укучысы белән узган, Сез яшь вакытта укыткан укучылар арасында аерма бармы?

**- Чор белән чор арасында аерма булмый мөмкин түгелдер инде. Хәзерге заман баласы техникага бәйле, укыту да башка төрлерәк алып барыла. Безнең чор укучысы акыллы, тыйнак, укытучыларга хөрмәте дә олы иде. Хәзерге укучыларга да җаваплылык зур, чөнки имтиханнар катлаулы. Ләкин укытучы бурычы гына үзгәрми – ул белем һәм тәрбия бирергә тиеш.**

- Лилия апа, Сез бит озак еллар дәвамында директор вазифасын башкарган җитәкче дә. Шул ук вакытта рус телен тирән өйрәтүче оста мөгаллимә дә. Бу йөкне бергә алып бару өчен күпме көч, вакыт кирәк булгандыр. Бигрәк тә ул заманның хуҗалык эшләре күп кул көче сорагандыр. Шулар турында әйтеп китсәгез иде.

**- Һәрбер хезмәт түземлелек, тырышлык сорый. Минем өчен директор эше күп көч сораган, вакыт таләп иткән бурыч иде. Җитәкче булу беркайчан да җиңел түгел инде ул. Хезмәттәшләрең белән бергә эшли алганда гына ул авырлыкларны җиңеп чыга аласыңдыр. Ул вакытта мәктәп мичкә утын ягып җылытыла иде. Утын әзерләү һәм төрле төзелеш эшләре бик авыр бара иде. Юл йөрер өчен транспорт чарасы юк дәрәҗәсендә**.

- Яңадан мөмкинлек бирелсә, сайлаган һөнәрегезгә тугры калыр идегезме?

- **Икенче яшьлегебез кайтса да, һич икеләнмичә, укытучы һөнәрен сайлар идек.**

- Замир абый, авыл балаларына чит тел укыту ул заманда нинди дәрәҗәдә иде. Ата-аналар бу дәрескә ничек карый иде? Гомумән, әти-әниләр мәктәп белән тыгыз элемтәдә тордымы?

**- Ул вакытта барлык фәннәр дә рус телендә укытылды. Татар теле белән чуаш теленә укучылар төркемнәргә аерылып керә иделәр. Чит тел буларак немец телен укыттым. Әти-әниләр баласы белемле булсын өчен телләр өйрәнүгә, әлбәттә, җаваплы карыйлар иде. Мәктәп белән элемтәләре һәрчак тыгыз булды. Мәктәп белән гаилә бердәм булганда гына баланы дөрес тәрбияләп булганын аңлап эшләдек.**

-Бүгенге укучыларга нинди теләк теләр идегез?

**- Тормышлары матур булсын, сәламәт булсыннар, тырышып укып зур кешеләр булуын телибез**. **Теләкләребез һәрберсенә барып ирешсен иде.**

Замир абый, Лилия апа, Сезгә әңгәмә өчен зур рәхмәт. Армый-талмый белем бирүегез белән халык алдында хөрмәт казангансыз. Мәктәп коллективы исеменнән Сезгә олы рәхмәтебезне белдерәбез. .

**Әңгәмәне VIII сыйныф укучысы Нәзирә Әхмәтова яздырды**

## / Рәсми хәбәрләр /

Май ае, тулаем алганда, IV чирекне һәм II яртыеллыкны йомгаклау чаралары белән үтте. IX, XI сыйныф укучылары йомгаклау имтиханнарына әзерләнсә, калган барлык сыйныфлар еллык йомгаклау контроль эшләрен башкарды. Мәктәптәге 54 укучының өлгереше буенча белем сыйфаты 72% тәшкил итә. II сыйныфтан Гафиятуллин Фаил, VIII сыйныфтан Әхмәтова Нәзирә чирекне, ә XI сыйныф укучылары Сафиуллин Илсур белән Магизов Илфир яртыеллыкны гел бишле билгеләренә генә тәмамладылар. 30 укучыга “4”,”5”ле билгеләре чыгарылды.

Май аенда мәктәп коллективы тарафыннан башкарылган җәмәгать эшләре;
- мәктәп һәм һәйкәл тирәсен җыештырылды;
- мәктәп бакчасына яшелчәләр утыртылды;
- авыл тирәсендәге чүплекләр чистартылды.

**Безнең укучылар сайлаган имтиханнар графигы**

| Төп дәүләт имтиханнары (IX сыйныф) | |
|---|---|
| 28 май | Рус теле |
| 4 июнь | География, химия, информатика |
| 6 июнь | Математика |
| 11 июнь | Биология |
| Бердәм дәүләт имтиханнары (XI сыйныф) | |
| 29 май | Математика (база һәм профиль) |
| 31 май | Химия |
| 3 июнь | Рус теле |
| 10 июнь | Җәмгыять белеме |
| 13 июнь | Биология |

## / Укучылар иҗаты /

**Читтән кайтканда**

Кунакка дип киткән идем
Ял итәрмен бераз, дип.
Әни кушкан вак-төяктән
Азрак арынырмын, дип.

Әй, йөримен урамнарда
Таш юллардан шакылдап.
Тик нигәдер ял итмимен,
Арып кайтам уфылдап.

Белдем нигә икәнен мин -
Һава җитми суларга
Җитми минем туган туфрак
Яланаяк чабарга.

Кайтам инде авылыма,
Әнә юлым күренә.
Торам таудан күзәтеп:
Авылым уч төбендә.

Бормаланып елга ага
Авыл читен сагалап.
Кайтып җиттем, туган ягым,
Алам хәзер кочаклап.

Арытмас мине моннан соң
Әнинең йомышлары.
Булсын иде һәркемнең дә
Кайтырга туган ягы.

***Нәзирә Әхмәтова***

**Туган як**

Туган якның матурлыгын
Күрә һәркем үзенчә
Мин дә аның гүзәллеген
Язам хәзер үземчә.

Елга буйлары турында
Бик күп шигырь-хикәят.
Безнең Чирмешән елгасы
Әйтерсең лә, әкият.

Язын тулып ага ул,
Бозлар сыешмый ярга
Шул вакытта җырчы кошлар
Ничек сайрыйлар талда.

Болыннары, тугайлары,
Мул уңышлы кырлары,
Тәмле сулы чишмәләре
Тырыш кыз һәм уллары.

Туган җирнең табигате
Саклыйк без, матурайтыйк.
Яшәсәк тә төрле җирдә,
Сагынышып, без кайтыйк.

**Әминә Туктамышева**



## / Күңелле тәнәфес /




### *Рамазан ае турында тест*

Быелгы май Изге Рамазан ае белән туры килде. Безнең укучылар арасында да ураза тотучылар һәм тәравих намазларына йөрүчеләр шактый. Түбәндәге тестны беренче эшләгән укучыны Рафик абыйларыннан **бүләк** көтә.

1. Коръәннең кайсы сүрәсендә Рамазан аенда ураза тоту фарыз кылынган? /а) Кадер; б) Бәкара; в) Ясин; г) Тин/.
2. “Ифтар” сүзе нәрсәне аңлата? /а)намаз исеме, б) хөрмә төре; в) уразада авыз ачу; г) кояш баеганнан соңгы намаз/.
3. Ураза тоту вакыты /а) кояш чыгу һәм баю арасында; б) таңнан алып караңгы төшкәнче; в) таң беленгәннән кояш баеганчы/.
4. Ураза тотучы нәрсәләрдән тыелырга тиеш? /а) көндез ашау-эчүдән һәм йоклаудан; б) ашау-эчүдән, нәфес теләкләреннән һәм гөнаһлардан; в) ашау-эчүдән һәм артык күп йоклаудан/.
5. Уразаны нәрсә боза? /а) үз теләгең белән косу; б) онытылып китеп ашау-эчү; в) сәхәр ашамыйча уразага керү/.
6. Рамазан аенда бирелергә тиешле садака /а) зәкәт; б) гошер; в) корбан; г) фитра/.
7. Кадер кичәсенең вакыты кайчан? /а) Рамазан ае эчендә; б) Рамазан ае ахырында; в) 27нче Рамазан кичендә/.
8. Кадер кичәсе хәерлерәк /а) мең сумнан; б) мең айдан; в) мең төннән; г) мең көн ураза тотудан/.
9. Рамазан ае тәгәлләнгәннән соңгы бәйрәмнең гарәпчә исеме /а) гайдел-әдха; б) гайдел-фитр; в) гайдес-саум; г) гайдел-ураза/
10. Рамазаннан соңгы ай /а) Шәүвәл; б) Рәҗәб; в) Зөлхиҗҗә/.

## / Котлыйбыз! /




Ямьле май аенда туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыз Хәбибрахманов Ильясны, Туктамышева Әминәне, Магизов Илфирны, Гыйльметдинова Әлфинәне чын күңелдән тәбрик итәбез, ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар телибез.

Башлангыч сыйныф укытучысы Рузилә апа Хәйруллинаны, безне тәмле ашлары белән сыйлаучы Рәмия апа Сәгдиеваны да туган көннәре белән котлыйбыз. Ныклы сәламәтлек, гаилә тормышларының матурлыгын, эшләрендә уңышлар теләп калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары:**
**Әминә Туктамышева** **Алия Гыйззәтуллина**
**Виктория Нукина** **Нәзирә Әхмәтова**
**Зөлфирә Сафиуллина** **Рузилә Мөхәммәтова**
**Сара Насыйрова**